ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. № 387-103/кс-2022

«Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2020 №303-124/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың эчә торган суга, ташландык су агызуга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 27.11.2020 №303-124/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 №505-163/кс-2021 карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 27.11.2020 №303-124/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 10.12.2021 №505-163/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
27.11.2020 №303-124/кс-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 № 387-103/кс-2022 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2021-2023 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | | |
| 1 | «Питрәч коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ*, технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | |
| 1.1 | Кощаково авыл җирлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 22,74 | 26,59 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 23,73 | 27,58 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 23,73 | 27,58 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 24,61 | 37,86 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,24 | 42,98 |
| 1.2 | Пановка авыл җирлеге кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 23,20 | 23,30 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 23,96 | 24,27 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 23,96 | 24,27 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 25,88 | 26,17 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,24 | 28,37 |
| 1,3 | Кулай, Ленино-Кокушкино, Питрәч авыл җирлекләре кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 23,25 | 28,71 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 24,17 | 29,77 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 24,17 | 29,77 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 25,11 | 39,64 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,24 | 45,10 |
| 1.4 | Белкино, Екатериновка, Кибәч, Кибәк, Кавал, Күн, Керәшен Сәрдәсе, Надеждино, Татар Казысы, Пимәр, Татар Тау Иле, Чыты, Шәле, Шигали, Янсуар авыл җирлекләре кулланучылары | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 23,25 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 24,17 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 24,17 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 25,11 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 26,24 | |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 № 387-103/кс-2022
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» МУП өчен 2021-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Питрәч коммуналь җылылык челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | | |
| 1.1 | Эчә торган су | | | | | | |
| 1.1.1 | Кощаково авыл җирлеге кулланучылары | 2021 | 1 065,98 | x | - | 9,91 | 1,18 |
| | | 2022 | x | 1 | - | 9,91 | 1,18 |
| | | 2023 | x | 1 | - | 9,91 | 1,18 |
| 1.1.2 | Пановка авыл җирлеге кулланучылары | 2021 | 528,20 | x | - | 3,26 | 0,5 |
| | | 2022 | x | 1 | - | 3,26 | 0,5 |
| | | 2023 | x | 1 | - | 3,26 | 0,5 |
| 1.1.3 | Белкино, Екатериновка, Кибәч, Кибәк, Кавал, Күн, Керәшен Сәрдәсе, Колай, Ленино-Кокушкино, Надеждино, Татар | 2021 | 12 036,59 | x | - | 8,98 | 1,18 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Казысы, Пимәр, Татар Тау Иле, Питрәч, Чыты, Шәле, Шигали, Янсуар авыл җирлекләре кулланучылары | 2022 | x | 1 | - | 8,98 | 1,18 |
| | | 2023 | x | 1 | - | 8,98 | 1,18 |
| 1.2 | Су агызу | | | | | | |
| 1.2.1 | Кощаково авыл җирлеге кулланучылары | 2021 | 1 303,20 | x | - | - | 0,53 |
| | | 2022 | x | 1 | - | - | 0,53 |
| | | 2023 | x | 1 | - | - | 1,70 |
| 1.2.2 | Пановка авыл җирлеге кулланучылары | 2021 | 1 518,95 | x | - | - | 0,24 |
| | | 2022 | x | 1 | - | - | 0,24 |
| | | 2023 | x | 1 | - | - | 0,24 |
| 1.2.3 | Кулай, Ленино-Кокушкино, Питрәч авыл җирлекләре кулланучылары | 2021 | 6 280,52 | x | - | - | 0,91 |
| | | 2022 | x | 1 | - | - | 0,91 |
| | | 2023 | x | 1 | - | - | 2,36 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге